# Габдулла Тукай (1886-1913).



- Мөхәммәтгариф углы Габдулла Тукай 122 ел элек 1886 елны апрельнең 26-да Казан артындагы Кушлавыч авылында мулла гаиләсендә дөньяга килгән. Биш ай чагында аның әтисе, ә 4 яшьлек чакта әнисе дә үлеп китә. Габдулла Тукай кече яшьтән дөм ятим калып, кулдан кулга күчеп йөрү михнәтләрен күргән. Тукай тормышын өч чорга бүлеп була: беренчесе – Кырлай, икенчесе – Уральск, өченчесе – Казан чоры.



- ***Кырлайда** Сәгъди абзый йортында үткән берничә ел яшь Габдуллага крестьян тормышының авырлыгын һәм матурлыгын аңлау юлында беренче тәҗрибәне биргән. Сәгъди абзый Тукайны эшкә өйрәтте һәм хезмәт иясенә хөрмәт тәрбияләде. Кырлайда Габдулла укырга йөри башлый. Кырлай мәдрәсәсендә булачак шагыйрьнең белем нигезе салына. Кырлайда туган беренче уй-тойгылар Тукай поэзиясенең күп кенә илһамлы юллары, темалары булып китүе дә мәгълүм. "Шүрәле" әкияте үзе генә дә Кырлай истәлегенең гүзәл бер шигъри һәйкәле итеп санала. "Пар ат" һәм "Туган җиремә" кебек шигырьЛәре дә Кырлай истәлекләре белән рухланган.*

- 1895 елда Габдулла Тукай Уральскига атасының сеңелесе Газизә Забирова тәрбиясенә алына. Шунда ул мәдрәсәгә укырга керә. “Мотыйгыя” мәдрәсәсендә башкалардагы кебек вактөяк кысынкылыклар булмаган. Анда шәкертләргә өлешчә ирек бирелгән. Шуның өстенә, 20-нче йөз ахырларында Рәсәйдә мәгърифәтчелек һәм яңача укыту хәрәкәтләре көчәя. Булачак шагыйрь Габдуллага шушы шартлар иҗатын ачылуга ярдәм итәләр.

- 1905 елгы революция Уральск шәһәрен дә тетрәтте. “Фикер”, “Әлгасрел-җәдит”, “Уклар” исемле беренче татар телендә гәҗитә һәм журналлар чыга башлый. Тукай шул басмаларда хәреф җыючы, төзәтүче, хәбәр җыючы, хәтта мөхәррир булып та эшләде. Бигрәктә татар телендәберенче юмористик һәм сатирик басма булган “Уклар” журналын ул тулысынча әзерләп һәм редакцияләп килә, аның үрнәгендә Тукай ирекле матбугатның нинди булырга тиешлеген күрсәтергә тели.

- 1907 елның көзендә Габдулла Тукай туган якларына кайта һәм Казанга килеп урнаша: “Әл - ислах” исемле журналда һәм “Китап” нәшриятында җиң сызганып эшләүчеләрдән берсе булып китә.
- Тукай – кыска гына вакыт эчендә шигъри осталык югарылыгына, сүз сәнгате серләрен ачуга ирешкән шагыйрьләрнең берсе. Аның поэзиясендә өч зур эстетик гореф-гадәт бергә очрашты: болар бик борынгыдан килә торган төрки поэзия, халык авыз иҗаты, рус һәм Көнбатыш поэзиясе.

- Тукайны халыкның тормышы, зыялыларның тәртибе борчый, ил эчендә һәм тышында булган күп кенә әһәмиятле вакыйгалар, хәлләр аның игътибарын җәлеп итә.
- Казанга килгәннән бирле беркая чыкмый яшәгән шагыйрь, сәламәтлегенең гаять начарлануына карамастан, 1911-1912 елларда берничә тапкыр сәяхәткә батырчылык итә: Идел буйларындагы тормыш белән таныша, Уфа, Петербург тарафларына юл тота...

- Шагыйрьнең саулыгы көннән-көн начарлана бара. 1913 елның апрельнең 15-дә 27 яшендә Габдулла Тукай якты дөньядан мәңгелеккә күчә. Никадәр генә газаплар кичерсә дә, бу фаҗигале, кыска гомер юлын горур атлап уза.



**Кабере.**

